ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РОМОДАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
РОМОДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 3 «09» февраль 2021е.

с. Ромодан

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 21 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2020 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе Беркетмәсен исәпкә алып, 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча

**карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 21 сентябрендәге 33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы йә шушы документлар белән эш итүче оешма | Муниципаль хезмәт алучыларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр;<br><br>Муниципаль хезмәт алучыларның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында вакыты чыккан бүтән бурычлары булуы (булмавы) турында белешмәләр.<br><br>Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр авария хәлләренә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә). | |

- 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч»

- 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«3) Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында авыл җирлеге сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.А. Чекалина**